| Республика Татарстан<br>Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге |
|---|---|

| КАРАР<br>31.10.2025 ел | КАРАР<br>№2 |
|---|---|

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлегенең Иске Имән торак пунктында гражданнарның 2026 елда үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә, авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Иске Имән авылы клуб бинасында 2025 елның 12 ноябренә 09.00 сәгатькә билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «I төркем инвалидлар, контракт буенча хәрби хезмәт, мобилизация буенча хәрби хезмәт һәм аларның гаилә әгъзалары, ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Иске Имән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Иске Имән торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу); Иске Имән торак пунктында вак таш япмасын ремонтлау (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, вак таш ташу һәм салу, грейдирлау);

2. Электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән тышкы яктырту челтәрләрен,трансформатор һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка

жиһазларны ремонтлау (Иске Имән торак пунктында урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);
3. Торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта Иске Имән торак пункты территориясен чабу (триммер алу, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү));
4. Иске Имән торак пунктында көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарның вакытлыча туплану урыннарын җыю (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
5. Иске Имән торак пунктында зур агачларны кисү (килешү буеча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү».

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Иске Имән авылы җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында кабул ителгән коннән 7 көн эчендә урнаштырыга.
4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Исламова